ГЛАВА СМАИЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СМӘЕЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

25 декабрь 2025 ел — № 6

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Смәел авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында»2025 елның 17 декабрендәге 28 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге Советының 29.05.2020 елның 126 номерлы карары белән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәләне тикшерүдә гражданнарның катнашу хокукларын үтәү максатларында гавами тыңлаулар уздыру турында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Киров өлкәсе белән чиктәш җирдә Татарстан Республикасы чигенә туры китерү мәсьәләсе буенча 2026 елның 14 гыйнварына 11.00 сәгатькә Смәел авыл җирлеге бинасында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар билгеләргә: ТР, Балтач муниципаль районы, Смәел авылы, Бауман ур., 69 йорт.

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 13 гыйнварына кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Балтач муниципаль районы, Смәел авылы, Бауман урамы, 69 йорт (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы). Консультацияләр өчен телефон: 8 (843)68-3-91-12.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) һәм «Хезмәт» матбугат-редакция газетасында

бастырып чыгарырга. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Смәел авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:

- Смәел ав., Бауман ур., 50 йорт,
- Сизнер ав., Совет ур., 24 йорт урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Смәел авыл җирлеге башлыгы Йосыпов Р.Г.